

# белый голубь

# ак күгәрчен

*Шагыйрь Расих Ханнанов истәлегенә*

ПРИ ПОДДЕРЖКЕ
ПРЕЗИДЕНТСКОГО ФОНДА
КУЛЬТУРНЫХ ИНИЦИАТИВ

6+

**Расих Ханнанов**
**Гульчачак Ханнанова**

# Ак күгәрчен. Шагыйрь Расих Ханнанов истәлегенә

*http://www.litres.ru/pages/biblio_book/?art=67768839*
*SelfPub; 2022*

## Аннотация

«Белый голубь» – так переводится название поэтического сборника, в котором собраны стихи 71 участника одноименного конкурса для начинающих поэтов-песенников, пишущих стихи на башкирском и татарском языках. Он проходил с октября 2021 по май 2022 года. По-башкирски название конкурса переводится как «Аҡ күгәрсен», по-татарски – «Ак күгәрчен». Его инициаторы – Союз писателей и администрация Кармаскалинского района Башкортостана – «малой родины» поэта Расиха Ханнанова, памяти которого посвящен конкурс. Песни на стихи этого автора широко известны в татарском и башкирском сообществе с 1950-х годов и считаются «золотым стандартом» национальной эстрады двух народов. Проект поддержан Президентским фондом культурных инициатив. В книге собраны стихи участников конкурса из Башкортостана, Татарстана, Москвы, Самарской, Челябинской, Московской областей, Пермского края, Чувашии, Литвы.

# Содержание


Расих Нургали улы Ханнанов 9
АК КҮГӘРЧЕН – ОҖМАХ КОШЫ 11
ӘТКӘЙ 12
ЯЛГЫЗ АККОШ КҮЛЛӘРДӘ 13
Розалина Йосыпова 14
АК КАЛФАК 14
Әлфиә Шамсутдинова 17
БЕЗ БИТ ШАТЛЫК ТӨРКЕМЕ 17
ЧИБӘР ЕГЕТ 19
Люция Аблеева 21
ТУГАН ЯККА КАЙТТЫМ 21
Мәсүфә Әюпова 23
САГЫНУ 23
САБАНТУЙ 25
Флюр Абдракипов 27
УФА КИЧЛӘРЕ 27
РЕЗИДАЛАР 29
Рәфига Усманова 30
АЛМАЛАР ӨЗЕЛДЕ, ӨЗЕЛДЕ 30
ЦУНАМИ 32
Венер Фаттахов 34
ӘТКӘЙ ЙОРТЫ 34
АК ЙОЗАКЛЫ АК ИШЕК 36

Фәния Габидуллина 38
ТӨШЛӘРЕМНӘН ГЕНӘ ЮГАЛМА 38
МАЯГЫМ БУЛ 39
Илгиз Әхмәтов 41
РЕКВИЕМ 41
ӨЛГЕРМӘДЕК 43
Сәрия Вахитова 45
БЕЗ БИТ БЕРГӘ (дуэт) 45
Сөмбелә Ибраһимова 47
ЧИШМӘЛӘР 47
АКЛЫК ИЛЕНДӘ 48
Әлфиә Латыпова 49
ТУЗГАНАК БУРАННАРЫ 49
АК ӨМЕТЛӘР 51
Юныс Миңлемәхәммәтов 53
КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ 53
КӨТ, ТУГАН ЯК 54
Мәйрүзә Насырова 56
ЧИТКӘ КИТКӘННӘН СОРА 56
ҖЫРЛА ЙӨРӘК ҖЫРЛАРЫҢ 57
Земфир Әхъяров 58
ТАҢ ҖИЛЛӘРЕ 58
ГҮЗӘЛЕМ 59
Гөлфия Гыйзәтова 60
ҖАН ДУСЛАРЫМА 60
Рәзилә Низами 61

ҖИЛӘКЛЕ ҖӘЙ 61
ЯЗНЫҢ КҮЗЛӘРЕ 62
Әнвәр Шарипов 63
КАР КЫЗЫ 63
Тәнзилә Әмирхан 64
КАЙДА МИНЕМ ЯШЬЛЕГЕМ? 64
АК КҮГӘРЧЕН 66
Ландыш Насыйрова 68
ӘНИЕМ 68
ЯРА 70
Лилия Хисәметдинова 71
УРМАНДА 71
Эльвира Альшина 73
СИНЕҢ ЙӨРӘГЕҢ 73
Лилия Вәлишина 75
САРЫ ЯФРАК 75
Зөлфия Газиева 77
СИН КАЙЛАРДА? 77
БУЛ ДУСЫМ 78
Нажия Гәрәева 79
КӨЗГЕ УЙЛАНУЛАР 79
Гөлназ Гафарова 80
ТУГАН КАПКА 80
ШОМЫРТ КҮЗЛӘР 81
Гузалия Гизатуллина 82
ВАКЫТ АТЫ 82

Камилә Латыпова 84
КҮБӘЛӘКЛӘР 84
Лидия Мавлютова 86
КЫСТЫБЫЙ 86
Рүзидә Фазлыева 87
ТАМЧЫ 87
МИН РОМАШКА ТӨЙМӘСЕ ТӨСЛЕ 88
Ильдар Хафизов 89
КӨЛ ӘЛЕ БЕР 89
БАРМЫ СИНЕ МИНДӘЙ ЯРАТКАН 90
Рәис Нәбиуллин 91
ОНЫТМАГЫЗ, ТУГАННАР 91
Лилия Кашапова 93
ЯШЬЛЕК ТАҢЫНДА 93
Дина Хайруллина 94
БАБАЕМ ҺӘМ БӘБӘЕМ (шаян җыр) 94
АК ФӘРЕШТӘ 95
Миңлекәүсүрия Нуруллина 96
МОҢЛЫ КӨЙ 96
АК МУЕНСА 98
Ришат Гыйлемханов 99
ЯШЬЛЕГЕМ ИЛЕ 99
Ралия Гизатуллина 101
ТУГАН ТЕЛЕМ 101

# Расих Ханнанов
# Ак күгәрчен. Шагыйрь Расих Ханнанов истәлегенә

**«Ак күгәрчен» –** ике тугандаш, башкорт һәм татар телләрендә иҗат итүче җыр авторлары өчен конкурс.

Ул шагыйрь Расих Ханнанов истәлегенә багышлана. Аның җырларын Башкортстанның һәм Татарстанның күренекле җырчылары 1950 еллардан башлап башкарган һәм башкара. Конкурс, җырга салырга мөмкин булган шигырьләргә багышланып, 2021 елның 28 октябрендә шагыйрьнең тууына 90 ел тулган көндә старт алды.

Аны оештыру идеясе белән Башкортстанның Кырмыскалы районы – Расих Ханнановның кече ватаны – һәм Башкортстан Республикасы Язучылар берлеге чыкты. Проект Мәдәни башлангычларның Президент фонды ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

2022 елда конкурста Башкортстан, Татарстан республикаларыннан, Мәскәү, Самара, Пермь, Ульяновск, Вильнюс һәм башка төбәкләрдән башкорт һәм татар телендә язган 60 шагыйрнын катнашты. Жюри составына күренекле әдәбият белгечләре, Башкортстан һәм Татарстанның легендар җырчылары керде. Жюри рәисе – композитор, Башкортстан Республикасының халык артисты, Татарстан Республикасының

Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Рим Хәсәнов булды.

Бу китапка конкурста катнашкан авторларның шигырьләре тупланды.

# Расих Нургали улы Ханнанов

Башкорт АССРының атказанган мәдәният эшлеклесе, Башкортстан Республикасының «Халыклар дуслыгы» ордены кавалеры, Татарстан Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияткә керткән өлеше өчен» мактау билгесе иясе.

Ул «сугыш чоры балалары» буынына карый: 1931 елда Кырмыскалы авылында туган, сугыш чорының барлык авырлыкларын кичергән, яшьли әтисен югалткан, өлкәннәргә ярдәм итеп, «Фронт өчен, җиңү өчен» девизы астында колхозда эшләгән.

Ватанпәрвәрлек һәм төрле милләт кешеләренең үзара ярдәмләшеп яшәү рәвешенә ул гомер буе тугры калды. Иҗат юлын район гәзитендә башлап, ул бик тиз абруйлы журналистка әверелә, Уфага, «Кызыл таң» гәзитенә эшкә чакырыла, биредә 40 ел эчендә әдәби хезмәткәрдән баш мөхәррир вазыйфасына кадәр юл үтә.

Расих Ханнанов әдәбиятка 1950 елларда килә, проза, поэзия, пьесалар яза. Аның 30 китабы, компакт-дисклары, аудиокитаплары дөнья күрде. Аның пьесалары буенча спектакльләр К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры, Сибай драма театры, Мәскәү, Үзбәкстан, Казахстан халык театрларында сәхнәгә куелды.

Шагыйрьны яраткан жанры – робагыйлар, ул – меңнән ар-

тык фәлсәфи дүртьюллыклар авторы. Популяр «Туган тел» телеканалы аның шигырьләренә яңы жанр – «шигъри паузалар» – циклын иҗат итте.

Башкорт һәм татар телләрендә язган җырлары шагыйрьгә зур танылу алып килә. Башкортстанның иң күренекле композиторлары Рим Хәсәнов, Тәлгать Шәрипов, Данил Хәсәншин һәм башкалар тарафыннан аның шигырьләренә 200дән артык җыр языла. Аларны Башкортстан һәм Татарстанның легендар җырчылары Илфак Смаков, Хәйдәр Бигичев, Идрис Газиев, Зәки Мәхмүтов, Радик Гәрәев, Гали Хәмзин, Нәзифә Кадыйрова башкарды.

Бу җырлар конкурсларда берничә тапкыр җиңү яулады: мәсәлән, «Күр әле бер генә» җыры Швециядә узган Халыкара конкурста Гран-прига лаек булды, «Ялгыз аккош күлләрдә» Татарстанда «Ел җыры» дип танылды.

Алсу Сафина «Әткәй» җырын Казанның 1000 еллыгы уңаеннан оештырылган тантаналарда башкарды. «Минем Уфам – Уралның саф гөле» җыры өчен шагыйрь Уфада «Башкала казанышы» премиясенә лаек булды.

Расих Ханнанов яшь журналистлар һәм әдәбият сөючеләрнең тулы бер буынын тәрбияләде, аларга укучы һәм тыңлаучы белән үзара бәйләнеш булдыруда һәрвакыт ярдәм итәргә омтылды. Шуңа күрә «Ак күгәрчен» конкурсын аның истәлегенә багышлау турында карар кабул ителде. 2020 елда вафатына кадәр соңгы язылган җыры «Ак күгәрчен» дип аталганлыктан, конкурс шулай дип исемләнде.

# АК КҮГӘРЧЕН – ОҖМАХ КОШЫ

*Тәрәзәм төбенә тышкы яктан*
*Көн дә ак күгәрчен куна.*
*Куна да ул, күзен мөлдерәтеп,*
*Миңа карап тора тын гына.*

*Кайдан килә ул, бармы хуҗасы,*
*Әллә югалтканмы оясын?*
*Ялгызлыкта үзең калсаң гына,*
*Читләр хәлен нечкә тоясын!*

*Ул соңласа, мин борчыла башлыйм,*
*Әйтерсең лә, нәни туганым,*
*Һәм сизәм мин шул чак күңелемнең*
*Нәфис хисләр белән тулганын.*

*«Куып җибәр!» – диләр. Бу мөмкинме?*
*Аның йөрәге дә ялкындыр.*
*Хакым бармы начарлык эшләргә,*
*Бәлки, ул кош синең җанындыр.*

# ӘТКӘЙ

*Минем әткәй көн дә эшкә китә,*
*Арып кайта аннан кичләрен.*
*Елмаюы итеп алып кайта,*
*Шәфәкъләрнең алсу төсләрен.*

*Әткәй, әткәй, синнән башка тагын*
*Кем бар шундый бала бәгырьле?*
*Кояш сыман әнкәй берәү булса*
*Син дә безгә шулай кадерле.*

*Минем әткәй көн дә эшкә китә,*
*Йолдызларны кайта ияртеп.*
*Йолдызлар да йоклап китә кебек*
*Әтиемнән әкият сөйләтеп.*

# ЯЛГЫЗ АККОШ КҮЛЛӘРДӘ

*Күл өстендә ялгыз аккош йөзә,*
*Нигә ялгыз, нигә пары юк?*
*Парсызларның күңелләре зарлы,*
*Парлыларның гына зары юк.*

*Минем дә бар иде, аккошкаем,*
*Җан дускаем, очар канатым.*
*Әллә инде артык яратканга*
*Юлларымда аны югалттым.*

*Парсыз калса кабат кайтмый, диләр,*
*Кайта икән, кайта аккошлар.*
*Кошларны да, кешеләр шикелле,*
*Үзе белән йөртә язмышлар.*

*Төннәрендә үзәк өзгеч тавыш,*
*Телеп үтә күлнең өсләрен.*
*Аңлар өчен аккош сагышларын*
*Белү кирәк сөю телләрен.*

# Розалина Йосыпова

# АК КАЛФАК

*Ак калфаклар каралмасын,*
*Заманның җилләрендә.*
*Һәр гүзәл зат бәхет күреп,*
*Яшәсен илләрендә.*

*Кушымта:*
*Ак калфак, ак калфак,*
*Кал син һәрчак ак һәм пакъ.*
*Калфак иман билгесе,*
*Калфак күңел көзгесе.*

*Ак калфак, ак калфак,*
*Һәр чак ап-ак калачак.*
*Калфак сафлыкка төрер,*
*Калфак бәхет китерер!*

*Ак калфаклар саргаймасын,*
*Сандыкның төпләрендә.*
*Ак калфаклар – ак күгәрчен,*

*Булсын ил күкләрендә!*

*Ап-ак калфак – ак иман ул,*
*Ул Туган Ил, туган тел.*
*Милли көйләр, моңлы җырлар,*
*Гөреф-гадәт, саф күңел.*

*Ак калфак киеп әйләнә,*
*Күчәрендә Җир Шары.*
*Ак калфак нуры яктырта,*
*Чиксез Җиһан юлларын!*

*Речитатив:*
*Дөнья авыр дип яшәмик,*
*Барысы да бер уза.*
*Аклык, пәкълыкка чакыра,*
*Ак калфак башыбызда.*

*Әнкәй сөте кебек ап-ак,*
*Без кигән ап-ак калфак.*
*Безгә ал таң, ак бәхетләр,*
*Вәгъдә итә ул һәр чак.*

*Ап-ак булсын, гел пак булсын,*
*Карлардан ап-ак калфак..*
*Без рухлы дип, тарихлы дип,*

*Хәтерләтеп торачак.*

*Без динле дә, иманлы да,*
*Без данлы булдык һәр чак.*
*Кисәтеп тора бу хакта,*
*Безнең башта ак калфак!*

*Әбкәм-әнкәмнең калфагы,*
*Кызыма калыр бер көн.*
*Мин дөньяда иң чибәр кыз,*
*Дип сөенер ул һәр көн.*

*Ак калфак һәм түбәтәйләр,*
*Бер ядькәр буыннардан.*
*Бер изге истәлек бит ул,*
*Әби һәм бабайлардан!*

## Әлфиә Шамсутдинова

# БЕЗ БИТ ШАТЛЫК ТӨРКЕМЕ

*Исәнмесез, милләттәшләр!*
*Сәламлибез без сезне.*
*Шатлык алып килдек сезгә –*
*Без бит шатлык төркеме!*
*Шат–шат–шат.*

*Шат, шат шатлык без,*
*Җырлыйбыз да биибез.*
*Гүзәл татар телебезне,*
*Данлы татар телебезне*
*Зурлыйбыз, кадерлибез.*

*Шатлык алып килдек бүген*
*Сезнең һәммәгезгә дә.*
*Бергәләп күңел ачарбыз*
*Бик рәхәт булыр безгә.*
*Шат–шат–шат.*

*Төркемебез безнең – «Шатлык»,*

*Шатлыклар өләшәбез.*
*Әйдәгез әле бергәләп*
*Җырлыйбыз да биибез.*
*Уйныйбыз да көләбез.*

*Шатлыклар өләшәбез.*
*Шат–шат–шат.*
*Җыр, моң, сафлык өләшәбез,*
*Шатландырып һәркемне.*
*Сер бирмибез, сынатмыйбыз –*
*Без бит шатлык төркеме!*
*Шат – шат – шат.*

# ЧИБӘР ЕГЕТ

*Серле карашларың белән*
*Син текәлеп карадың.*
*Син текәлеп карадың да,*
*Йөрәккә ук кададың.*

*Кушымта:*
*Ник текәлеп карадың да,*
*Гашыйк иттең үзеңә?*
*Кара әле чибәр егет,*
*Тагын кара күземә!*

*Көнләшәм сине кызлардан,*
*Гел сине уйлап йөрим.*
*Күреп торам кызларның да*
*Һәммәсе сине күзли.*

*Кушымта:*
*Гашыйк итеп син үзеңә,*
*Битараф каласыңмы?*
*Яныймнан үтеп китәсең,*
*Мин көтәм карашыңны.*

*Түземлегем бетте минем,*
*Үзем киләм каршыңа.*
*Биергә сине чакырам,*
*Ни диярсең ансына?*

*Әйдә, әйдә чибәр егет,*
*Бие, карап күземә!*
*Серле карашларың белән*
*Гашыйк иттең үзеңә.*

# Люция Аблеева

# ТУГАН ЯККА КАЙТТЫМ

*Туган якка кайттым,*
*Миләш өзеп каптым*
*Күзләремнән тамды яшьләрем.*
*Ачы түгел миләш,*
*Сагынылган кардәш,*
*Кайтармыйча торды эшләрем.*

*Йортлар инде башка,*
*Алар күккә аша*
*Берсе-берсе белән ярышып.*
*Ләкин урам таный,*
*Миңа бармак яный*
*Әллә чынлап, әллә шаярып.*

*Миләш, синең җимеш*
*Бигрәк тәмле, имеш.*
*Туган якта микән үскәнгә?*
*…Төштем сукмаклардан*
*Килеп аръяклардан*

*Тик уйларым йөгерә үткәнгә.*

# Мәсүфә Әюпова

## САГЫНУ

*Кемнәр уйлап чыгаргандыр*
*Бу сагыну хәлләрен.*
*Серләремне сезгә чишәм,*
*Өзгәләнгән мәлләрем.*

*Кушымта:*
*Бүген төннә төшләремә*
*Зинһар өчен кер әле.*
*Яратуларыңны сөйләп,*
*Җанга җылы өр әле.*

*Сагынуларны исәпләргә*
*Үлчәмнәр җитмәс иде.*
*Күңелдәге бу сагышлар*
*Мәңгегә китмәс инде.*

*Сагынуга дәва булыр*
*Кош теледәй хат салсаң.*
*Син – минеке, мин – синеке,*

*Дигән антны акласаң.*

# САБАНТУЙ

*Гомер бакый минем халкым*
*Сабантуйлар уйнаган.*
*Бар милләтне бер мәйданга*
*Менә шулай җыйнаган.*

*Кушымта:*
*Гөрли бүген туган якта*
*Ямьле сабантуйлары.*
*Хезмәт сөйгән якташларның*
*Матур хәтта уйлары…*

*Гасырлардан гасырларга*
*Бу йола күчә килә.*
*Берәү җырлый, берәү бии,*
*Ә берәү атта җилә.*

*Кушымта:*
*Бәхет, шатлык, сөенечкә*
*Уралган бүген халкым.*
*Икмәк үстеручеләрнең*
*Беләләр бездә хакын!…*

*Туй булгач, туй булсын әле*
*Уйнагыз, гармуннарым!...*
*Кунакларның күңелендә*
*Калсыннар җыр-моңнарым...*

*Кушымта:*
*Чигелгән сөлге эләкте,*
*Иң өлгер, иң шәп атка.*
*Сабантуйда табышканнар*
*Калмыйлар бездә ятка!*

# Флюр Абдракипов

# УФА КИЧЛӘРЕ

*Күңел түремдә саклана*
*Уфа кичләре.*
*Яшлек моңына уралган*
*Сирен исләре.*

*Кушымта:*
*Серле Уфа кичләрендә*
*Мин сине таптым.*
*Гомерлеккә ярым булдың,*
*Сине яраттым.*

*Агиделдә балкып яна*
*Уфа утлары.*
*Онытылмас хискә чумган*
*Шул минутларым.*

*Җилкендерә саф мәхәббәт,*
*Якты хыяллар.*
*Сөю тулы йөрәгемә*

*Дөнья сыядыр.*

# РЕЗИДАЛАР

*Резида гөлләре үсә*
*Гөлбакчамның түрендә.*
*Берсе ямьли тирә якны,*
*Берсе йөрәк түремдә.*

*Кушымта:*
*Мәхәббәтем Резидамны*
*Бигрәк инде яратам.*
*Назлы гөлләремә күмеп*
*Тик үземә каратам.*

*Резида гөлләрем матур,*
*Бүтәнгә чагыштырмам.*
*Сөйгән ярым Резиданы*
*Ятларга алыштырмам.*

*Резидам минем язмышым,*
*Көтәм сине күрергә.*
*Бакчабызда гөлләр үсәр*
*Бергә булыйк гомергә.*

# Рәфига Усманова

# АЛМАЛАР ӨЗЕЛДЕ, ӨЗЕЛДЕ

*Алмалар исенә исерден,*
*Уч төптәген жиргә төшерден.*
*Карашың бүтәнгә күчерден,*
*Хыянәтең авыр кичердем.*

*Кушымта:*
*Алмалар пештеләр алланып,*
*Йөрәгем утына ялманып.*
*Алмалар өзелде, өзелде,*
*Бакчамда көз инде, көз инде.*

*Пешкәне сутлыдыр алманың,*
*Борылып күзең дә салмадың.*
*Синнән башка яши алмамын,*
*«Син – алсу алмам» – дип алдадың.*

*Алмаларны жыеп алыгыз,*
*Сөлгеләргә юып салыгыз.*
*Алмадай гомердә гомергә*

*Пар алмадай бергә калыгыз.*

*Кушымта:*
*Алмалар пешеләр алланып,*
*Йөрәгем утына ялманып.*
*Алмалар өзелде, өзелде,*
*Бакчамда көз инде, көз инде.*

# ЦУНАМИ

*Бар дөньямны ялмап алды*
*Утлы хис, тынмас тойгы.*
*Сихермени? Йөрәгемне*
*Үзенә бәйләп куйды.*

*Кушымта:*
*Әйтеп торам: «Ярамый!».*
*Аңламый, тыңламый.*
*Мәхәббәтем, – дулкын, вулкан,*
*Йөрәгемдә цунами.*

*Цунами,*
*Цунами,*
*Йөрәгемдә цунами…*
*Хисләр ташты, йокы качты,*

*Күңел кая тартыла?*
*Дулкын сымак чайпалдырып,*
*Әллә кая чакыра.*
*Кушымта.*

*Давыл, гарасаты белән*

*Күңелдә диңгез шаулый.*
*Бер канунга да буйсынмый,*
*Дөньядан нидер даулый.*

*Кушымта:*
*Әйтеп торам: «Ярамый!»*
*Аңламый, тыңламый.*
*Мәхәббәтем дулкын, вулкан,*
*Йөрәгемдә цунами.*

*Цунами,*
*Цунами,*
*Йөрәгемдә цунами.*

## Венер Фаттахов

# ӘТКӘЙ ЙОРТЫ

*Күләгәсендә чәчәкләр,*
*Тәрәзәдә алмагач,*
*Үпкәлидер алмалары*
*Җыючысы булмагач.*

*Кушымта:*
*Әткәй йорты, әнкәй йорты,*
*Алмалары коелган.*
*Эх, чабып бер кайтыр идем,*
*Юллар инде уелган.*

*Алмагачның күләгәсен*
*Баскан алтын яфраклар.*
*Тик төшләргә генә керә*
*Туып үскән туфраклар.*

*Өем түгел, илем дә бит*
*Чүп-үлән асларында.*
*Эх, әтиле йортка кайтып*

*Үләнгә капланырга!*

# АК ЙОЗАКЛЫ АК ИШЕК

*Ак йозаклы йорт алдында*
*Калды яшьлек еллары.*
*Җәйләр саен бер урарга,*
*Эх, кая соң юллары?*

*Кушымта:*
*Ак йозаклы ак ишекне*
*Ак томаннар каплаган.*
*Ничә еллар инде кайтып*
*Шакыр вакыт тапмаган.*

*Ак йозаклы ак ишекне*
*Ачы җилләр шакыйдыр.*
*Күпләр микән туган якка*
*Кайтыр вакыт тапмыйдыр!?*

*Җилләр белән колакларга*
*Килә ишек тавышы.*
*Ак йозакта ак томандыр,*
*Эх, эчетә сагышы!*

*Томан аша чая яшьлек,*

*Кайтыгыз, дип чакыра.*
*Кайтып шунда, ишек шакып,*
*Эх, торырга чак кына!*

# Фәния Габидуллина

# ТӨШЛӘРЕМНӘН ГЕНӘ ЮГАЛМА

*Сагынуларым булып кайтасыңмы,—*
*Көн дә сине төшләремдә күрәм.*
*Ник әйттем соң юксынырлык булгач:*
*«Сине түгел, башка берне сөям»…*

*Томан арасыннан елмаясың,*
*Күзләреңдә сөю уты һаман.*
*Йөгереп барып кочаклыйсы иде,*
*Тик арада ята куе томан.*

*Үкенүләрем булып керәсеңме*
*Төшләремә минем кабат-кабат.*
*Күңелемнең бер ярсу чагында*
*Үзем әйттем: «Башка берне ярат!»*

*Хәзер менә сагынып көтеп алам,*
*Төшләремдә елмай кабаттан.*
*Күкрәгеңә ятып елар идем…*
*Ни кызганыч, инде таң аткан.*

# МАЯГЫМ БУЛ

*Мин бәхетле, —*
*Яннарымда тик син булсаң.*
*Иңнәремдә*
*Кулларыңның көчен тойсам.*

*Мин өметле*
*Күзләреңдә нурлар күрсәм,*
*Шул нурларда*
*Йөрәгемә юллар үрсәң.*

*Сабыр идем.*
*Ашкынырга син өйрәттең.*
*Салкын идем, —*
*Учагымда куз көйрәттең.*

*Иркәләмә, —*
*Назга туймас сабый иттең.*
*Үпкәләмим, —*
*Көлгә калып янып беттем.*

*Мин гашыйкмын*
*Гайрәт ташкан буй-сыныңа,*

*Тик ашыкмыйк*
*Сихри хискә буйсынырга.*

*Чуалтырбыз*
*Сихри серле ул йомгакны.*
*Югалтырбыз*
*Бергә йөрер ул сукмакны.*

*Мин табынам*
*Синең сүзгә, назга, моңга.*
*Юк, абынмам,*
*Булсаң маяк ул упкында.*

# Илгиз Әхмәтов

# РЕКВИЕМ

*Тузгытып олы юл тузанын*
*Булачак солдатлар тезелде.*
*Кем көлде, елады: кайдадыр*
*Соңгы кыл зыңгылдап өзелде…*
*Бер мизгел – аралар өзелде*
*Бетмәстәй чакрымнар тезелде*
*Ә җанга – алдагы кайгылар,*
*Мәнгелек югалту сизелде…*
*Солдатлар тезелде,*
*Хыяллар төзелде —*
*Өметләр озелде…*
*Ничек тә түзелде…*
*Керфекләр аркылы күз яше сөзелде…*
*Малайлар хезмәткә киттеләр —*
*Җаннарын тупларга җиктеләр…*
*Кан акты… Хыяллар беттеләр…*
*Үлемгә балалар киттеләр…*
*Үлемнән яшәүгә бу ара*
*Ни гаеп, бу хезмәт – ни чара?*

*Я Афган, я Чичен сугышы*
*Көйдерә сабыйлар сулышын…*
*Кемнәрдер югала…*
*Кем читкә юл ала…*
*Шат йөзләр карала…*
*Балалар баш сала…*
*Кайгылы ананың зиһене тарала…*
*Онтылды гудоклар тавышы.*
*Тик хәтер бер тынга карышып*
*Бирмәскә тырыша үткәнне:*
*Онытма аналар көткәнне!*
*Тормышның тузанлы юлыннан,*
*Мәңгелек чәчәкле болыннан*
*Яшь буын тынычлап атласын,*
*Кан койган корбанны акласын!*
*Йөрәктә сакласын!*
*Һәм горур атласын!*
*Ватанын якласын!*
*Дошманнан сакласын!*
*Туган җир ул изге –*
*Сугыштан сакласын!*

# ӨЛГЕРМӘДЕК

*Кайгырсаң да, саргайсаң да*
*Яшьлек калды еракта*
*Сагынмыйча мөмкинме соң*
*Ул бит бәхетле чаклар!*
*Их, бу дөнья, нигә бик тиз*
*Әйләнә тәгәрмәчең?*
*Кадерлеләр ташлап китә*
*Сагыш суыра көчем…*
*Анда калды басуларым,*
*Гөлчәчәкле тугаем*
*Артта калгач кына күрәм,*
*Чагыштырып, мөгаен…*
*Их, бу дөнья, нигә бик тиз*
*Әйләнәнә тәгәрмәчең?*
*Кадерлеләр ташлап китә*
*Без яшибез кем өчен…*
*Яшь барганга яңарадыр*
*Шул чагу хәтирәләр*
*Әби-бабай иркәләүге,*
*Болындагы тирәкләр…*
*Их, бу дөнья, нигә бик тиз*
*Әйләнә тәгррмәчең?*

*Кадерлеләр ташлап китә…*
*Күрәсең, синең үчең.*

# Сәрия Вахитова

## БЕЗ БИТ БЕРГӘ (дуэт)

*Егет. Иртә таңнан күзем ачсам,*
*Уемда син.*
*Күктән төшкән илаһи зат*
*Минем өчен.*
*Алларыңда телсез калам*
*Сине күрсәм*
*Уйларымда тик син генә,*
*Көтәм, көтәм..*
*Кыз. Адымнарым очкан коштай —*
*Барам сиңа,*
*Бәхетемнең ачкычларын*
*Табам синдә.*
*Адашмамын булган чакта*
*Куллар кулда.*
*Киртәләрне бергә җиңик*
*Барыр юлда.*
*Кушымта.*
*Безнең йөрәк бергә тибә —*
*Без бит бергә.*

*Ходай безне кавыштырган*
*Бар гомергә.*
*Сөю догаларын укып*
*Яшик бергә.*
*Бәхет, сөю нурын сибеп Тирә-юньгә.*

*Кыз. Әгәр сиңа кит дисәм дә,*
*Син ышанма*
*Тел әйтсә дә, йөрәк әйтмәс,*
*Сөю барда*
*Синсез яшәү яшәү түгел,*
*Сөям сине.*
*Киләчәгемнең бәхетен*
*Күрәм синдә.*

*Егет. Сукыр кебек адашсам да*
*Мин аппагым,*
*Мәхәббәткә тап төшерми*
*Мин сакlargeмын*
*Йөрәгемдә сиңа булган*
*Сөю ята.*
*Сиңа булган саф хисләрем*
*Чәчәк ата.*

# Сөмбелә Ибраһимова

## ЧИШМӘЛӘР

*Мең аһәңле була икән*
*Чишмәләрнең агышлары,*
*Кешеләр күк аларның да*
*Буладыр үз язмышлары.*
*Әбиемнең чулпы чыңын*
*Хәтерләтеп ага берсе,*
*Таш астыннан бәреп чыккан –*
*Шаулап тора икенчесе.*
*Өченчесе сагышлырак,*
*Челтерәве салмак икән.*
*Суга килми сылу кызлар…*
*Шуңа да ул моңлы микән?*
*Күпме хисләр, күпме серләр!*
*Су тавышы, кош авазы…*
*Чишмәләрдә туган якның*
*Чал тарихы, кайтавазы.*

# АКЛЫК ИЛЕНДӘ

*Кышкы кичтә ак тәңкәләр*
*Җемелдәшә ай нурында.*
*Карларның бар матурлыгы-*
*Энҗе булып балкуында.*
*Төшә карлар бөтерелеп,*
*Йолдызларны ияртеп тә.*
*Бу сафлыкка сокланырлык,*
*Бу аклыкны сөярлек тә.*
*Көмеш урам уртасыннан*
*Атлап килә ике гашыйк.*
*Урамда – кыш, күңелләре*
*Киткән кыштан саубуллашып.*
*Аклык илен кичә-кичә*
*Атлый алар таңга таба.*
*Бәхет теләп үзләренә*
*Чәчәк – чәчәк карлар ява.*

# Әлфиә Латыпова

# ТУЗГАНАК БУРАННАРЫ

*Тузганаклар гөлләмәсен*
*Чәчләремә кададың.*
*Назлар тулы карашыңны*
*Мөхәббәткә юрадым.*

*Мөхәббәт түгел икән дә,*
*Шаяру бары гына.*
*Чәчәкләрең әйләнделәр*
*Тузганак мамыгына.*

*Сары, сары, сары микән*
*Сөюләрнең уз төсе?*
*Узең – ялкын, узең – салкын*
*Нәкъ тузганаклар төсле.*

*Ышандым карашларыңа,*
*Эредем кочагыңда…*
*Сузләрең ап-ак мамыктай*
*Жилләргә очты гына.*

*Иркәләп кара күземә,*
*Ал мине кулларыңа.*
*Икәүләп кереп адашыйк*
*Тузганак бураныңа.*

# АК ӨМЕТЛӘР

*Хыялларым, җимерелеп,*
*Җаннарыма ауган сыман.*
*Чак-чак торган күңелемә*
*Ап-ак томан сарган сыман.*

*Ак томаннар арасыннан*
*Ак өметләр юлын табар,*
*Сүнде дигән йолдызларым*
*Яр-яңадан балкып янар.*

*Ак томаннар, ак томаннар,*
*Югалыгыз, таралыгыз!*
*Сүнеп барган өметләрем,*
*Боре булып яралыгыз!*

*Өметләрең өзелгәндә,*
*Авыр була яшәүләре.*
*Күңел көтә җылы сүзләр,*
*Иркә, назлы дәшүләрне.*

*Кыл өстендә калганда да,*
*Бирешмә син, өмет өзмә.*

*Ходай үеп бәхет бирер*
*Түзә белеп түзгәннәргә.*

# Юныс Миңлемәхәммәтов

## КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ

*Дөньяларга кеше елап туа,*
*Вакыт җиткәч, китә елатып.*
*Кыскамы ул, озынмы ул – гомер,*
*Күз яшьләре йөри озатып.*

*Шатлыкмы ул, олы кайгымы ул,*
*Күз яшьләре битне чылата.*
*Адәм баласының күңеле тула —*
*Күңел тулы булгач – елата!*

*Күз яшьләре авыртуны баса,*
*Күз яшьләре аклый караны.*
*Кайчак яшьләр оныттыра ала*
*Күңелләрдә булган яраны…*

*Дөньяларга кеше елап туа,*
*Алдан белә әллә язмышын?*
*Алдан белми шул ул, белгән булса,*
*Кабатламас иде ялгышын.*

# КӨТ, ТУГАН ЯК

*Туган илем, газиз җирем,*
*Кайтыр якка чыгам бүген,*
*Очар кошлар белән бер иштән.*
*Алар белә сиңа юлны,*
*Сагыш булып туган моңны*
*Кошлар тавышында ишетәм.*

*Сагындыра, юк чаралар,*
*Кабат мине чакыралар*
*Челтрәп аккан йөгерек чишмәләр.*
*Иксез-чиксез урманнарым,*
*Иркен болын, киң кырларым*
*«Кайт син, балам!» – диеп дәшәләр.*

*Яшәсәм дә күптән читтә,*
*Очрашуны өзелеп көтәм,*
*Сагынганнар аңлар хәлемне.*
*Туган якка җаным тарта,*
*Хатирәләр якынайта*
*Күрешүләр көткән мәлемне.*

*Кайтыр җирең булу-бәхет,*

*Туган ягым, син бары көт,*
*Читтә гомер иткән улыңны.*
*Җилгә кушып салам алдан,*
*Юл күрсәткән кошчыклардан*
*Отып алган сагыну җырымны.*

# Мәйрүзә Насырова

# ЧИТКӘ КИТКӘННӘН СОРА

*Чит җирләргә китәбез дә*
*Шунда үтә гомерләр,*
*Туган яклар искә төшсә,*
*Тула безнең күңелләр.*

*Яшьләр тула күзебезгә,*
*Моң саркыла күңелгә,*
*Очып кына кайтыр идек,*
*Куллар канат түгел лә.*

*Чит якларда үтә гомер*
*Чишмә буен сагынып,*
*Төштә сайрый сандугачлар*
*Талларында кагынып.*
*Җиләк пешкән аландагы*
*Сукмаклар сагындыра…*
*Туган җирнең ямен, тәмен*
*Читкә киткәннән сора.*

# ҖЫРЛА ЙӨРӘК ҖЫРЛАРЫҢ

*Яр астында челтер чишмә*
*Җырлап ага таңнарда,*
*Өздереп сайрый сандугач*
*Су буенда талларда.*

*Сандугачтай тал тибрәтеп*
*Моңнарым сибим микән?*
*Әллә челтер чишмә булып*
*Ярлардан тибим микән?*

*Сандугачның тавышын алдым —*
*Тибрәлмәде талларым,*
*Челтер чишмә, таушын алгач,*
*Ташлап китте ярларын.*

*Күктән дәште җырчы тургай*
*Сибеп дәртле моңнарын:*
*Үз тавышың табып җырла,*
*Җырла йөрәк җырларың.*

# Земфир Әхъяров

# ТАҢ ҖИЛЛӘРЕ

*Таң җилләре, беләсеңме,*
*Нигә исәләр?*
*Алар, исеп, миннән сиңа*
*Сәлам илтәләр.*
*Таң җилләре көн дә исә,*
*Исә дә китә.*
*Синең елмаюың миңа*
*Гомергә җитә.*
*Син киләсең, кояш кебек,*
*Җиргә нур сибеп.*
*Таң җилләре кала синең*
*Битеңнән үбеп.*
*Нигә, иркәм, таң җилләре*
*Булмадым икән?!*
*Мин гомергә таң җилләре*
*Була алмам микән…*

# ГҮЗӘЛЕМ

*Сине эзләп иркәм, бу дөньяда*
*Кошлар белән оча сәламем.*
*Сәламнәрем барып җитәр кебек*
*Бар җиренә бик зур галәмнең.*
*Искән җилләр аша җибәрәм мин*
*Кайнар хисләр тулы сөюемне*
*Белсәң иде, иркәм, сине сагынып*
*Айлар, еллар буе көюемне…*
*Йолдызларга әйтәм сөюемне —*
*Бәлки, алар сиңа җиткерер?*
*Сөю белән тулган сәләмеңне*
*Бәлки, алар миңа китерер?*
*Еракмы икән гүзәлем?*
*Ялгызлыкка ничек түзәрмен!*
*Мин барыбер сине эзләрмен,*
*Алларыңа чәчәк тезәрмен.*

# Гөлфия Гыйзәтова

# ҖАН ДУСЛАРЫМА

*Бәхет икән якын дуслар булу,*
*Алар булгач рәхәт, күңелле.*
*Кыен чакта хәл дә белә алар,*
*Күтәрә дә белә күңелне.*

*Замананың ыгы-зыгысында,*
*Мәшәкатләр ерып яшибез.*
*Шул юлларны узган вакытларда*
*Дусларыбыз белән көчле без.*

*Рәхмәт әйтәм якын дуслар сезгә,*
*Сау-сәламәт, имин булыгыз!*
*Очрашулар үзе гомер бит ул,*
*Еш-рак төшсен безгә юлыгыз.*

*Йөрәк үзе сайлап ала диләр*
*Җан дусларын гомер юлында.*
*Мин дә горурланып әйтә алам*
*Чын дусларым сезнең турында.*

**Рәзилә Низами**

# ҖИЛӘКЛЕ ҖӘЙ

*Ямьле җәй урталарында*
*Кызарып пешә җиләк.*
*Җиләк кенә чакларыбыз,*
*Түгелмәсен пар чиләк.*

*Кушымта:*
*Тау башында пар җиләк,*
*Җиләкле безнең төбәк.*
*Дөньяның бар ямен тоеп*
*Парлашып яшәү кирәк.*

*Җәйне күрми йөрмә әле,*
*Җиләкләргә йөре әле.*
*Чәчәкле җәй үтеп китәр,*
*Җәйнең тәмен бел әле.*
*Тау башында пар җиләк,*
*Җиләкле безнең төбәк.*
*Дөньяның бар ямен тоеп*
*Парлашып яшәү кирәк.*

# ЯЗНЫҢ КҮЗЛӘРЕ

*Язның күзләре ниндиме? —*
*Тал бөреләре төсле.*
*Таллардан күзне алалмыйм, —*
*Мөлдерәмә бөресе.*

*Язның күзләре ниндиме?*
*Ташкын суныкы төсле.*
*Үзе тирән, үзе кайнар,*
*Ә үзе шаян, хисле!*

*Язның күзләре ниндиме?*
*Хас синең үзең төсле.*
*Керфек очларыңа тамам*
*Кояшлы яңгыр төсле.*

# Әнвәр Шарипов

# КАР КЫЗЫ

*Кар кунган якаларыңа,*
*Кар кунган иңнәреңә.*
*Теләгем шул: насип бул син*
*Бары үз тиңнәреңә.*

*Кар кунган синең башлыкка,*
*Һәм чигә чәчләреңә.*
*Гашыйк булдым мин шул чакта*
*Керфегең бәсләренә.*

*Кар кызы булып киләсең*
*Минем каршыларыма.*
*Дәва булыр микән бу кар*
*Йөрәк ярсуларына.*

*Карны эретер идем мин,*
*Кочакка керсәң әгәр…*
*Кояш чыкты – эретер инде,*
*Күк йөзе дә зәп-зәңгәр.*

# Тәнзилә Әмирхан

## КАЙДА МИНЕМ ЯШЬЛЕГЕМ?

*Кайда минем яшьлегем,*
*Эзләрен бит югалттым,*
*Сине эзләп, яшьлегем,*
*Сагыш-моңга уралдым.*

*Юксындыра күп еллар,*
*Айлы кичтәге моңнар,*
*Үтсәм дә мин күп юллар,*
*Гармун күңелдә чыңлар.*

*Гармунда серле тавыш,*
*Сөйли тора үз хәлен,*
*Таратып ачы сагыш,*
*Әрнетеп йөрәк зарын.*

*Тәүге гомерем башы,*
*Еракларга юл алды,*
*Кайда яшьлегем юллары,*
*Сезне язмыш югалтты?*

*Әйтче сердәшем, гармун,*
*Кайда минем яшьлегем?*
*Еллар аша синең көйдә,*
*Гомер кичерә моң-зарым.*

# АК КҮГӘРЧЕН

*Ак күгәрчен бакчамда,*
*Оясы кар басмамда,*
*Гөрли таңнар атканда,*
*Сагыш-моңга батканда.*

*Кушымта:*
*Ак күгәрчен ак карда,*
*Гөр-гөр килә бакчамда,*
*Пар иясе һәр җанда,*
*Парлы булсын һәрчакта.*

*Гөр-гөр килеп күтәрелә,*
*Канат кагып күкләргә,*
*Ялгыз кыен үткәрелә,*
*Охшаш гомер күпләргә.*

*Ак күгәрчен ярпынып,*
*Кемне соң эзли икән?*
*Өзелеп сөйгән ярлары,*
*Ансызмы яши икән?*

*Канатлары каерылмасын,*

*Үз парын эзли-эзли,*
*Тапканнан соң аерылмасын,*
*Ятларны көйли-көйли.*

# Ландыш Насыйрова

## ӘНИЕМ

*Шундый кадерле син, әнием,*
*Шундый акыллы син бигрәкләр*
*Бәхетле булсын балам, дип,*
*Тырыштың син бөтен көчеңә.*
*Тормышыма терәк булдың,*
*Начар сүзләрдән сакладың,*
*Авыр чакта син минем*
*Башларымнан сыйпадың.*
*Әни канатлары – ышык,*
*Курчалый ул тормыш җиленнән.*
*Жылы сүзе белән жылыта*
*Күңелемнең сүрән көннәрен.*
*Якты йөзе белән яктырта*
*Язмышымның моңсу даласын.*
*Назлы күзе белән назлый*
*Күзләремнең дымлы камышын.*
*Мин кайтканда сөенеп, көтеп тора*
*Сагындым шул, кызым!-дип әйтә.*
*Дөньядагы иң кадерле сүздер*

*Минем йөрәк бары ишеткән.*

# ЯРА

*Йөрәкләрдә яра төзәләме?*
*Төзәлә ул, кала җөйләре.*
*Ул күренмәсә дә кешеләргә,*
*Кала мәңгелеккә эзләре.*
*Йөрәкләре яралылар күпме?*
*Әйтеп булмый читтән карауга.*
*Яралылар бары үзе генә*
*Тозын сибеп тора ярага.*
*Яра төзәлсә дә, барыбер әрни,*
*Сыкрый, булмый үзгәртеп.*
*Була бары йөрәгеңне тотып,*
*Дару белән генә төзәтеп.*
*Басып тора бары бер уч дару*
*Яралы йөрәкнең сызлавын.*
*Кай вакытта ул да файда бирми,*
*Ничек түзеп лә мин яшәрмен!*

# Лилия Хисәметдинова

## УРМАНДА

*Урманнар шаулый, җырлыйлар*
*Искәндә җиләс җилләр.*
*Җанга рәхәт, куанычлы,*
*Урманда үтсә көннәр.*

*Каеннар шаулый, имәннәр,*
*Наратлар тезелгәннәр.*
*Чыршылар шундый искиткеч!*
*Юкәләр бөгелгәннәр.*

*Урманда һәр үткән мизгел*
*Җанга тынычлык бирә.*
*Кош сайраганга кушылып,*
*Моңлап җырлыйсы килә.*

*Килми торсаң, нидер җитми,*
*Күңелдә бушлык була.*
*Урманнан көч, хисләр алып,*
*Яшәүгә дәртең тула.*

*Урманнарга йөрегез сез!*
*Анда бар яшәү көче.*
*Җаныгызга ямь алыгыз,*
*Нур һәм яктылык өчен.*

# Эльвира Альшина

## СИНЕҢ ЙӨРӘГЕҢ

*Очраткач сине, мин аңладым,*
*Ни була ул икән – күңел тынычлану.*
*Шикләнүемне тиз ташладым,*
*Синең йөрәгең – минем сыену.*

*Ни була ул икән – күңел тынычлану?*
*Синең йөрәгең – минем сыену.*

*Мәхәббәт сүзе алды яңа мәгънә,*
*Яныңда тоям мин зур шатлык,*
*Иң караңгы вакыт бүген безгә,*
*Синең йөрәгең – төнге яктылык.*

*Яныңда тоям мин зур шатлык,*
*Синең йөрәгең – төнге яктылык.*

*Хәзер төгәл сиңа әйтә алам:*
*Миңа берни кирәкми синсез.*
*Үз фикеремә мин тугры калам,*

*Синең йөрәгең миңа булды диңгез.*

*Миңа берни кирәкми синсез,*
*Синең йөрәгең – диңгез.*

# Лилия Вәлишина

## САРЫ ЯФРАК

*Агачтагы сары яфрак*
*Төште минем учларыма.*
*Агачтагы сары яфрак*
*Керде никтер күңелемә.*

*Кулымдага соңгы яфрак*
*Карый өзеп күзләремә.*
*«Хуш бул», – диеп дәшә йөрәк.*
*Ява яңгыр пыскып җиргә.*

*Әкрен, әкрен шаулый туфрак.*
*Яна сагыш кулларымда.*
*Моңсу, моңсу инде бигрәк,*
*Җирдә кала бушлык кына.*

*Күз яшемне тыеп калам.*
*Бушлык җиңә кайчагында.*
*Күз яшедәй тама тамчы*
*Соңгы төснең яфрагына.*

*Яңгыр үтә, бушлык йота.*
*Катып калган күз яшедәй*
*Балкый тамчы соңгы төстә.*
*Бушлык канун. Әмма…*
*Әмма хисләр ташый…*

# Зөлфия Газиева

# СИН КАЙЛАРДА?

*Син таптың да мине, мин югалттым.*
*Син кайларда хәзер? Кайларда?*
*Син табыл да, ярдәм итче миңа,*
*Чуалган уйларны җайларга.*

*Мин эзләдем сине, тик уңышсыз.*
*Хәзер инде син мине эзлә.*
*Кабат икәү күзгә-күз карашып,*
*Очрашмыйча, син инде, түзмә.*

*Меңнәр арасыннан бары сине*
*Кирәк булды миңа сайларга.*
*Пәйда булчы, тагын, алларымда.*
*Син кайларда хәзер? Кайларда?*

# БУЛ ДУСЫМ

*Бураннарда җылыт мине,*
*Бул ялкын.*
*Челләләрдә җиләс ясар*
*Җил, салкын.*
*Син-болыным, зәңгәр күктә-*
*Болытым.*
*Ап-ак чәчәккә күмелгән*
*Шомыртым.*
*Йөрәгеңдә тибрәлеп нечкә кылың,*
*Шул кылларга кунып сайрар*
*Былбылым.*
*Коеп яуган яңгырым син*
*Җиһанда.*
*Мин тамчылап Сөю җыям,*
*Учымда…*
*Бул Кояшым, Язым, Аем,*
*Йолдызым.*
*Һич икеләнми әйтерлек,*
*Чын дусым…*
*Күктә янган, син, иң якты*
*Йолдызым.*

# Нажия Гәрәева

## КӨЗГЕ УЙЛАНУЛАР

*Көзге җилдә шыбыр-шыбыр коя*
*Каеннарым алтын тәңкәләр.*
*Кем газиз баласын өзелеп лә сөя?*
*Ул бит безнең әткәй-әнкәйләр.*
*Җылысын тоеп әни кулының*
*Тан аткач йокымнан уянам.*
*Күптән бәлигъ булган зур улымны*
*Буй җитмәсә дә сөям һаман.*

*Балаларның йөрәгендә калсын*
*Әнкәй кочагының җылысы.*
*Көзге яңгыр яуганда исенә алсын,*
*Сагынып ла килсен елыйсы.*
*Хисләр йомшак күңелле итәләр,*
*Кешелекле булсын кешеләр!*
*Ил тормышы алга китәр иде*
*Күбрәк булса хисле кешеләр.*

# Гөлназ Гафарова

## ТУГАН КАПКА

*Теләсәм дә бик еш ача алмыйм*
*Туган өем – нигез капкасын,*
*Язмыш җиле аны каралтса да,*
*Кайгы җиле килеп какмасын.*
*Туган капка һәркем өчен ачык*
*Әткәм-әнкәм үзе шикелле,*
*Сагынулар сагышларга салды.*
*Кайтам әле, кайтам бу юлы.*

*Ачып чыгып туган йорт капкасын*
*Олы юлга аяк бастым мин,*
*Дус-иш булдым бик күп чит-ятларга.*
*Сагынып көтеп алган, капкам – син.*
*Туган капка, зинһар, бикләнмәче,*
*Салдырмачы син үзеңә келә,*
*Ямансулап мине озатсаң да,*
*Исән – сау кайтуымны телә.*

# ШОМЫРТ КҮЗЛӘР

*Шомырт җыям, шомырт җыям,*
*Чиләкләрем тулганчы,*
*Шомырт җыям, сине уйлыйм,*
*Уйлыйм күңелем булганчы.*

*Шомырттай кара күзләрең…*
*Белсәң иде серләрен,*
*Озын керфекләр яшерә*
*Кемнәндер сөюләрен.*

*Шомырттай кар күзләрне*
*Көн дә килә күрәсем,*
*Ул кемнәрне сөя икән?*
*Эх, килә шул беләсем!*

*Шомырт җыям әрәмәдә,*
*Күзләреңдәй каралар,*
*Сөюемнән күпер салам,*
*Якынайсын аралар.*

# Гузалия Гизатуллина

## ВАКЫТ АТЫ

*Вакыт аты һич туктамый.*
*Гомер инде кичкә авыша.*
*Хисләр көчен авызлыклап,*
*Акыл белән күңел кавыша.*
*Җилләр тарый инде күптән*
*Ак кылганнар кунган чәчемне.*
*Яшьлек юләрлеге үткән:*
*Арттырасы килми яшемне.*
*Чигендереп дистәләбен*
*Кайтыр идем яшьлек елларга.*
*Шатлыгым канатларында*
*Шаян җилләр белән уйнарга.*
*Җил-давылларны иярләп,*
*Таулар җырын җырлап үтәргә.*
*Аллы-гөлле җәйгор нурын*
*Төсле җепләр итеп сүтәргә.*
*Сүтәргә дә, шул нурлардан*
*Язмыш сукмакларын чигәргә.*
*Һәрбер көнен бу гомернең*

*Күмеп яшәр өчен гөлләргә…*
*Вакыт аты һич туктамый.*
*Гомер инде кичкә авыша.*
*Юк, кирәкмәс кире кайту!*
*Рәхмәтлемен шушы язмышка.*

# Камилә Латыпова

# КҮБӘЛӘКЛӘР

*Күбәләкләр оча, күбәләкләр оча, кояшны бик каты сагынып.*
*Күбәләкләр оча, күбәләкләр оча, җәйге җылыга канатларын җәеп.*
*Үзләрен сакламыйлар җәйге көннәр буенча.*
*Көйләрен сайрамыйлар, җырлый да белмичә.*

*Бәгерем, йугерәм синең янга, бик соң аңлыйм…*
*Күңелемне карангылык баса, инде берүзем, куркам.*
*Безнең урамнар, нурлы күзләр – берсе дә онытылмый.*
*Бергә булган кадерле көннәр, томан кебек, еракта ери.*

*Күбәләкләр оча, күбәләкләр оча, кояшны бик каты сагынып.*
*Күбәләкләр оча, күбәләкләр оча, җәйге җылыга канатларын җәеп.*
*Үзләрен сакламыйлар җәйге көннәр буенча.*
*Көйләрен сайрамыйлар, җырлый да белмичә.*

*Инде тоела таң, төрле бизәкле төсләрдә.*
*Бик боектыр җаным, сүнәдер ул.*
*Юллар сузыла, гүя илтә мине бик ерак җирләргә.*
*Кайгыру һаман һаваларда йөри, йөрәгемдә кала мәңгегә.*
*Күбәләкләр оча, күбәләкләр оча.*

# Лидия Мавлютова

## КЫСТЫБЫЙ

*Кыстыбый, кыстыбый, кыстыбый:*
*Камырга бәрәнге кыстырган.*
*Онытып тәмеңне һич булмый:*
*Балачак кенемдә саклаганган.*

*Әбиләр, әниләр пешергән,*
*Җәймәләр тутырган бер өстәл.*
*Майланып авызда эрөгән,*
*Гомергә кыстыбый гел истә.*

*Балачак бик кыска дөньяда,*
*Сизелми бер үтә дә китә.*
*Язмышлар, узмышлар юлында*
*Бер гөнә нур булып «ялт!» – итә.*

*Әле мин ашамлык пешерәм,*
*Гел тәмле кыстыбый табында.*
*Оныклар кырына китерәм,*
*Тантана, бәйрәмнәр алдында.*

# Рүзидә Фазлыева

## ТАМЧЫ

*Юлда калган эзләреңә*
*Карап күзләрем талды.*
*Шул чагында моңсу гына*
*Эркелеп тамчы тамды.*
*Аңламыймчы, тама икән*
*Тамчыларның кайсысы?*
*Күзләремнең яше микән,*
*Әллә яңгыр тамчысы?*
*Аймылыш эзләрең юып,*
*Юлыма тама тамчы.*
*Күз яше ачы булса да,*
*Җырымнан китми калчы.*

# МИН РОМАШКА ТӨЙМӘСЕ ТӨСЛЕ

*Сагышланудан чәчемне*
*Сары төскә буядым.*
*Көзгегә карый алмыйча,*
*Авыр сулап куямын.*
*Син киткәч мине ташлап,*
*Ак күлмәгем кимәмен.*
*Мин ромашка төймәсе төсле,*
*Гүя саргайган төймәмен.*
*Өзгәләнгән күңелемнән*
*Тамып төшә күз яше.*
*Сөюемне әйттем сиңа,*
*Аңламадың – бик әче.*
*Сынып, сызлап бетәлмәслек,*
*Сагынуыма әйләндең.*
*Күктә никах укылмаган,*
*Язмышка кыз-сәйләннең.*

# Ильдар Хафизов

## КӨЛ ӘЛЕ БЕР

*Көл әле бер, дөньяңны онытып,*
*Сандугачлар отып сайрарлык.*
*Кара әле күзләрең тутырып,*
*Йөрәгемдә хисләр кайнарлык.*

*Көл әле бер, дөньяңны онытып,*
*Сагыш болытларын куарлык.*
*Боекларның күңел көзгесеннән*
*Моң-зар тузаннарын юарлык.*

*Көл әле бер, дөньяңны онытып,*
*Кабатланмас сихри чың булып.*
*Котылгысыз тарта мине һаман*
*Күзләреңнең тирән чоңгылы…*

# БАРМЫ СИНЕ МИНДӘЙ ЯРАТКАН

*Җирдә тагын берәү бармы икән*
*Сиңа миндәй бәхет теләгән?*
*Син кояшым гомер күгендәге,*
*Ә мин бары синең күләгәң.*

*Җирдә тагын берәү бармы икән*
*Минем кебек сиңа табынган?*
*Син йолдызым еллар томанында*
*Адаштырмас өчен кабынган.*

*Җирдә тагын берәү бармы икән*
*Минем кебек сине яраткан.*
*Исемеңне йөрәгендә туган*
*Җырларына кушып тараткан?*

*Җирдә бармы берәү синең өчен*
*Суга батып, утка керердәй?*
*Ә мин әзер икеләнеп тормый*
*Синең хакка җаным бирергә.*

# Рәис Нәбиуллин

# ОНЫТМАГЫЗ, ТУГАННАР

*Гомер бетеп, бакыйлыкка күчкәч,*
*Мин кайтырмын сезне сагынып.*
*Якты кояш булып, нурлар сибеп,*
*Алсу таңнар булып кабынып.*
*Яз керсәгез алма бакчасына,*
*Чәчкә аткан булыр алмагач.*
*Каршы алган сезне ул бакчада*
*Мин булырмын – сары сандугач.*
*Куандырып сезне тугайларда*
*Мин чәчкәләр булып үсәрмен.*
*Күңелегез мине сагынганда*
*Йомшак җилләр булып исәрмен.*
*Урманнарда әгәр адашсагыз,*
*Кәккүк булып сезне эзләрмен.*
*Сабантуйлар җитсә, зәңгәр күктән*
*Тургай булып сезне күзләрмен.*

*Яз керсәгез алма бакчасына,*
*Чәчкә аткан булыр алмагач.*

*Каршы алган сезне ул бакчада*
*Мин булырмын – сары сандугач.*
*Куандырып сезне тугайларда*
*Мин чәчкәләр булып үсәрмен.*
*Күңелегез мине сагынганда*
*Йомшак җилләр булып исәрмен.*

*Урманнарда әгәр адашсагыз,*
*Кәккүк булып сезне эзләрмен.*
*Сабантуйлар җитсә, зәңгәр күктән*
*Тургай булып сезне күзләрмен.*
*Сезнең белән бергә була алмам:*
*Кичерегез исән булганнар.*
*Сезгә минем бары тик бер теләк:*
*Онытмагыз мине, туганнар!*

# Лилия Кашапова

# ЯШЬЛЕК ТАҢЫНДА

*Ак күгәрчен тотып туй көнендә*
*Очырдык без яшьлек таңында.*
*Ак канатлы иң саф, иң шат көннәр*
*Искә төшә тагын, тагын да.*

*Хыялларның бергә йөзгән чагы,*
*Тормышларның гүзәл мизгеле.*
*Син бүген дә минем өчен кояш,*
*Галәм бүләгенең бер гөле.*

*Гөл-чәчәгем, кочам, күккә очам,*
*Мәхәббәтем, иркәм, юлдашым.*
*Сиңа бүләк булсын йөрәк җырым,*
*Бердәнберем, бәгьрем, кояшым!*

# Дина Хайруллина

## БАБАЕМ ҺӘМ БӘБӘЕМ (шаян җыр)

*Бабаемның җаны бәбәй*
*Бик ихлас ул, эчкерсез;*
*Яши бирә инде шулай –*
*Гомер сөрә мәкерсез.*

*Бабай эчендәге бәбәй*
*Кәефне кыра кайчак:*
*Үзен-үзе кимсеткәндәй*
*Әйткән сүзе шыр борчак.*

*Кайчак аның бабайлыгы*
*Үзен күрсәтеп ала:*
*Артык сакчыл, шикләнгәндәй*
*Йөзен җыерып тора.*

*Белми торам – кем эргәмдә –*
*Бабаймы, әллә бәбәй?*
*Якын минем күңелемә*
*Чал башлы олпат бәбәй.*

# АК ФӘРЕШТӘ

*Ак фәрештә оялаган*
*Ак каеннар башына.*
*Үткәрерме шул фәрештәң*
*Назлап Ходай каршына?*

*Йөрәгеңне ачтырыр ул*
*Үтеп күңел түренә.*
*Иңнәреңнән кочаклар ул*
*Сират күперләрендә.*

*Ак фәрештәң канат җәер,*
*Тазартыр күңел керен.*
*Сафлык белән тулган җанга*
*Күрсәтер изге юлын.*

*Ак фәрештә юллар сузыр*
*Тик ихлас җанга гына.*
*Дорфаларга авыр булыр*
*Ходайның каршысында.*

## Миңлекәүсүрия Нуруллина

# МОҢЛЫ КӨЙ

*Җәйге төндә нурлы ай яктысы,*
*Энә саплап чигу чигәрлек.*
*Кемдер берәү гармунында уйный,*
*Көе моңлы – узәк өзәрлек.*

*Сагышларын моңлы көйгә сала,*
*Айлы төндә йөри адашып.*
*Әйтимме әллә барып яннарына:*
*«Мин дә шул халәттә – адашың».*

*Гармунчының гармун телләрендә*
*Уз язмышы, узенең чарасы.*
*Минем язмышым да төзәлмәслек,*
*Мәңге сунмәс йөрәк ярасы.*

*Җәйнеңхозур айлы бу төнендә,*
*Кем икән соң йөри моң сибеп?*
*Кайтыр юллар тапмый яшьлегенә,*
*Хыялында йөри тилереп.*

*Әй уйнады гармун сыздырыплар,*
*Моңлы көйләр, җырлар таратты.*
*Йокыларны ачып, моңландырып,*
*Сагышлара салып юатты.*

# АК МУЕНСА

*Ап-ак җепләргә тезәләр*
*Ак сейләннән муенса.*
*Ходай безне кавыштырыр,*
*Язмышлар бергә булса.*

*Сәйлән муенса муенда,*
*Син гел минем уемда.*
*Ак муенса бүләк иттең,*
*Миңа сабантуенда.*

*Ап-ак муенса бүләгең,*
*Уртак микән теләгең.*
*Энҗе муенса бәхеткә*
*Булсын диеп теләдем.*

*Алтын-сәйлән муенса ла,*
*Миңа бик тә килешә.*
*Ут-суларны кичәр идем*
*Үзең булсаң янәшә.*

**Ришат Гыйлемханов**

# ЯШЬЛЕГЕМ ИЛЕ

*Кул сузам төшләрдә*
*Мин сихри илләрдә —*
*Тота алмыйм киек кошларны…*
*Очарга тырышам,*
*Канатлы кош сыман —*
*Тота алмыйм куып аларны....*
*Балачагым иле*
*Бик ерак та түгел!*
*Бүләк итә кайчак төшләрем…*
*Шул бала чакларны,*
*Шул узган яшьлекне*
*Сагынам, күз тулы яшьләрем!*
*Яшьлегем иленә*
*Бер кайтасы иде,*
*Үткәнгә, дуамал чакларга!*
*Дөньяны онытып,*
*Төшләрдә булса да*
*Телимен мин сиңа чумарга!*
*Мөлдерәмә яшьләр…*

*Инде йөрәк нишләр?*
*Үткәннәрне искә алганда…*
*Тик шулай да түзәм,*
*Карыйм балама —*
*Яшьлегем бит минем – аңарда!*

# Ралия Гизатуллина

## ТУГАН ТЕЛЕМ

*Татар булып тудым мин бу җиргә,*
*Татар рухлы, татар кызы мин!*
*Халкым, телем, гореф-гадәтләрем, —*
*Сездән башка беркем түгел мин!*

*Кечкенәдән туган телем мине*
*Җитәкләп алды да кулымнан,*
*Алып керде тормыш дәрьясына,*
*«Тайпылма! – дип барыр юлыңнан.*

*Шул юл буйлап һаман барам әле,*
*Туры гына түгел юлларым.*
*Зарланмыймын һич тә мин язмышка:*
*Алга әйди мине уйларым.*

*Әби-бабай, әти-әни миңе*
*Туган телле итеп үстерде.*
*Бишек җыры белән керде миңа*
*Туган телнең бетмәс кадере.*



Рәсих Ханнанов





Кырмыскалы авылында: Әнисе Оркыя һәм апасы Әнисә белән



Атасы Нургали (уңда) узенең хезмәттәшләре белән



Ерак көнсыгыш флотында хезмәт иткән вакытында



Хәрби хезмәттән соң



Туган авылында беренче музыкаль адымнар



Шигыйрьләр өстендә эш



Салауат дәүләт башкорт драма театры артислары белән



Күп санлы жырларының авторы композитор Рим Хәсәнов белән



Башкорт дәүләт филармониясы артислары белән



Иң беренче булып җырларын башкаручы хәләл җефете Люциә белән



Күренекле язучылар: Мустай Кәрим, Марсель Гафуров, Сафуан Әлибаев, Мөнир Әглиуллин белән




Ижади хезмәттәшләре: режиссер Байрас Ибрагимов, композитор Рим Хәсәнов һәм рәссам Васил Ханнанов белән



Рәсих Ханнановка Уфада мемориал такта ачканда

Главный портрет – фото Рамиля Кильмаматова. Остальные фото из семейного архива